РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д 8, с.Карамалы,
Азнакаевский муниципальный район
423301

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРАМАЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 8 нче йорт, Карамалы авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423301

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «01» ноября 2019г. № 47

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Октябрь-Бүләк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елның 15 ноябренә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Октябрь-Бүләк авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2019 елның 15 ноябре 14.00 сәгатьтән;
- үткәрү урыны-Октябрь Бүләк авылы, Октябрь Бүләк авылы мәдәният йорты залы;

1.3. 1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 05 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Карамалы авылы, Үзәк урам,8 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Октябрь-Булэк торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Октябрь-Булэк торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Булэк торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләү билгеләп, үзара салым кертү һәм

бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
-урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, Октябрь-Бүләк авылында килешү буенча эш өчен түләү;;
- Октябрь-Бүләк авылында юлларны кардан чистарту;

« РИЗА»　　　　　　　　　　«КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.  һәм  түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Карамалы авылы, Узэк ур., 8й.
3.  Әлеге карар  игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык:　　　　　　　　　　А.Р. Ногманов